**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

# КАРАРЫ

**егерме тугызынчы утырыш**

**«25» сентябрь 2023 ел № 105 Алан авылы**

**Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге советының 2015 елның 16 нчы июне №154 «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлегендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«13» сентябрь 2023 елгы Исорг-20920037-583-23/-20920037, номерлы Теләче районы прокуратурасының протестын карап чыгып, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге советының 2015 елның 16 нчы июне №154 «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлегендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау регламентын раслау турында» карарына (31.03.2016 № 24, 20.09.2018 № 107, 15.11.2021 № 55 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлегендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау регламентының 7.4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.4.2. Россия Федерациясе Президенты, Татарстан Республикасы Башлыгы (Раисе) мөрәҗәгатьләрен карау буенча йөкләмәләрне үтәү аерым контрольгә куела, аларны карау срогы 15 көнгә кадәр дәвам итә.».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

Алан авыл җирлеге башлыгы Б.Н.Хәсәнов